| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2018 Казан ш. № 3-9/э

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-15/э карары белән билгеләнгән дәвамлы хосусый тарифларга 2019 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә кирәкле тулай табышны дәвамлы индексацияләү ысулын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, җайга салынулы оешмаларның зарури тулай табышын исәпкә алып, «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә дәвамлы хосусый тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016-2020 елларга «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә хосусый тарифлар билгеләү турында» 10.12.2015 №3-15/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2016 № 3-10/э, 08.12.2017 № 3-10/э карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-15/э карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2018 № 3-9/э карары редакциясендә)

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән хосусый тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2016 | 818 122,36 | 20,58 | 1,92403 | 818 122,36 | 20,08 | 1,92535 |
| | | 2017 | 797502,20 | 20,40 | 1,87587 | 797502,20 | 21,83 | 1,87730 |
| | | 2018 | 835 828,71 | 24,40 | 1,94366 | 835 828,71 | 25,37 | 1,94463 |
| | | 2019 | 866 450,41 | 25,43 | 2,01500 | 866 450,41 | 27,18 | 2,01675 |
| | | 2020 | 881 222,86 | 20,58 | 2,07084 | 881 222,86 | 20,08 | 2,07034» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-15/э карарына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2018 № 3-9/э карары редакциясендә)

## «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2016-2020 елларга зарури тулай табышы (сарыфларга түләүне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы | 2016 | 67 347,83 |
| | | 2017 | 65 650,38 |
| | | 2018 | 68 805,42 |
| | | 2019 | 71 326,20 |
| | | 2020 | 72 542,27 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге